| Козгын козгынга очадыр<br>Козгын козгынга әйтә:<br>– Козгын! Карным бик ачадыр,<br>Кайда җим бар? – дип әйтә. | Ворон к ворону летит,<br>Ворон ворону кричит:<br>«Ворон, где б нам отобедать?<br>Как бы нам о том проведать?» |
| Козгын козгынга җавабән<br>Әйтәдер: – Мин җим табамын:<br>Яшел тугайда ятыр<br>Алдап үтерелгән батыр. | Ворон ворону в ответ:<br>«Знаю, будет нам обед;<br>В чистом поле, под ракитой<br>Богатырь лежит убитый. |
| Кемдер егетне үтергән,<br>Алган йөгерек атыны –<br>Белде бизәнеп утырган<br>Өендә яшь хатыны. | Кем убит и отчего,<br>Знает сокол лишь его,<br>Да кобылка вороная,<br>Да хозяйка молодая». |
| Дәрдемәнд «Козгын» [1: 56]. | Сокол в рощу улетел,<br>На кобылку недруг сел,<br>А хозяйка ждет милого,<br>Не убитого, живого.<br>А.С. Пушкин «Ворон к ворону летит…» [2: 75]. |

Бу әсәрнең авторы, үзен атамыйча, бары тик Дәрдемәнд[2] тәхәллүсенең беренче «Д» хәрефен кую белән канәгатьләнгән. Ләкин шунда ук шигырьнең тәрҗемә булуын искәртүне кирәк тапкан. Әмма оригинал шигырьнең исеме дә, авторы да күрсәтелмәгән. Классик рус әдәбиятын яхшы белгән татар зыялыларының бер өлешенә, күрәсең, бу искәрмәләр җитәрлек тә булгандыр. Күпчелек өчен исә татар каләме белән язылган шигырьне А.Пушкин белән бәйләү сер булып калгандыр. Пушкинның исем куелмаган бу шигыре 1829 нчы елда иҗат ителгән. Ул татарчага тәрҗемә вариантыннан күләменең дүрт юлга артыграк булуы белән дә аерылып тора.

Эзләнүләр бу шигырьнең дә рус шагыйренең оригинал әсәре түгеллеген күрсәтә. Инглизчә белмәгән А.Пушкин бу шигырьне Вальтер Скоттның (1771-1852), француз теленә тәрҗемә ителеп, 1826 нчы елда басылган Шотландия балладалары җыентыгыннан алган һәм аны «шотландская песня» дип атаган. Пушкин шул шигырьдәге биш строфадан өчесен тәрҗемә өчен сайлап алып, аның исемен («The Two Corbies») төшереп калдырган.

As I was walking all alane,
I heard twa corbies making a mane;
The tane unto the t’other say,
«Where sall we gang and dine to-day?»

In behint yon auld fail dyke,
I wot there lies a new slain knight;
And noebody kens that he lies there,
But his hawk, his hound, and lady fair.

His hound is to the hunting gane,
His hawk to fetch the wild-fowl hame,
His lady’s ta’en another mate,
So we may mak our dinner sweet.

«The Two Corbies» [3: 253].

Популяр инглиз һәм шотланд балладаларының иң тулы биш томлыгын 1882-1898 нче елларда бастырып чыгарган Фрэнсис Джеймс Чайлд бу халык җырының кайчандыр киң таралган «The Three Ravens» («Өч козгын») инглиз балладасы белән бәйләнешенә игътибар итә: «Яңгырашы буенча бу шигырь йомшак, кечкенә инглиз балладасының циник вариантына охшаган» [3: 253].

Оригиналның русчага һәм татарчага тәрҗемәләренә күз салсак, беренчедән, күләмнәренең төрле икәнлеге күренә. А.Пушкин оригинал текстка бик якын тора, шулай да, эчтәлеген саклап калу өчен, артык бер строфа өсти. Ә татар тәрҗемәчесе эчтәлекне кыскарта һәм шуның белән шотланд халык җыры күләмен саклый (дүртәр юллы өч строфа). «Д» шигырен иҗат иткәндә, бары тик Пушкин «тәрҗемәсенә», әллә шотланд оригиналына да таянганмы – монысы билгесез. Бәлки, ул рус шагыйре кебек үк французчага

[2] 1990 нчы еллардан шагыйрьнең тәхәллүсен «Дәрдемәнд» дип яза башладылар (Тәрҗемәче искәрмәсе).

ясалган тәрҗемә белән таныш булгандыр? «Д» инглиз телен дә, француз телен дә белмәгән, әмма аның танышлары арасында бу телләрдә сөйләшүчеләр, һичшиксез, булган. Шотланд һәм рус вариантларында өч җан иясе – лачын яки эт, ат, яшь хатын – егетне кем үтергәнен белеп торсалар, татар шигырендә исә бу хакта бары тик яшь хатын гына хәбәрдар. Мондый кыскартуга «Д» дип исемләнгән шагыйрьне нинди сәбәпләр этәргәнен ачыклау шактый кыен булса да, нәтиҗәсе ачык: татар версиясе ситуацияне төгәлрәк һәм ачыграк итеп тасвирлый, нокта куя. Оригиналның интонациясе һәм Чайлд тарафыннан күзәтелгән ниндидер циник яңгырашы татарчада, минемчә, Пушкин вариантына караганда ныграк сакланган.

Әсәрләрне шәрехләгәндә, тагын бер момент игътибарны җәлеп итә: бу ноктадан караганда да татар варианты шотланд оригиналыннан һәм рус тәрҗемәсеннән «өстенрәк» тора. Килеп чыккан ситуациянең ахырын төрле вариантларда тасвирлау турында сүз бара. Оригинал текстка таянсак, яшь хатын каһарманны кем үтергәнен белә. Биредә ачыктан-ачык «His lady's ta'en another mate» дип әйтелә [3: 253]. Пушкин исә ситуацияне бераз үзгәртә: яшь хатын үтерелгән каһарман-ирен көтми, ә аны үтергән кешене көтә: «А хозяйка ждет милого, не убитого – живого» [2: 75]. Димәк, исән калган кешенең үтерүче булу мөмкинлеге күренеп тора. Ә татар шигыренең ахыры чын-чынлап ике мәгънәле: яшь хатын, ирен үтерүченең кем икәнлеген белеп, өендә бизәнеп утыра. Ни өчен? Үзенең ирен көткәнгәме, әллә аның үтерүчесенме? Тәрҗемәче «Д» бу сорауга җавап бирми. Шигырь серле интонациясен шул рәвешле саклап кала – күрәсең, укучы аны үзе уйлап табарга тиеш була.

Ул вакытта киң таралган «Козгын» шигыренең татар авторына булган тәэсире шулай ук тулысынча ачык түгел. 1845 нче елда Эдгар Аллан По иҗат иткән «Козгын» шигырен С.А.Андреевский 1878 нче елда беренче тапкыр рус теленә тәрҗемә итә. 1911 нче елга кадәр шигырьнең русчага тугыз тәрҗемәсе билгеле (шулар арасында: 1892 нче елда – Дмитрий Мережковскийныкы, 1894 нче елда –Константин Бальмонтныкы) [4].

Дәрдемәнд – Закир Рәмиевнең (1859-1921) әдәби кушаматы. Ул – Оренбург шәһәр Думасы әгъзасы, беренче Дәүләт Думасы депутаты, икенчесендә һәм өченчесендә депутатлыкка кандидат, алдынгы татар мәктәпләренә ярдәм күрсәтүче, шөһрәтле «Вакыт» әдәби нәшриятының хуҗасы, әйдәп баручы татар басмаларыннан Оренбургтагы «Вакыт» газетасының (февраль 1906 нчы ел – гыйнвар 1918 нче ел) һәм «Шура» журналының (гыйнвар 1908 нче ел – декабрь 1917 нче ел) нашире, тәрбия, мәгариф, мәдәният үсешенә һәрдаим матди ярдәм күрсәтүче меценат. Шул ук вакытта ул Уралдагы алтын приискаларының бай хуҗасы. Дәрдемәнд – XX йөз башында кулларына каләм алып, үз фикерләре, уй-хисләре, тойгылары һәм өндәүләре белән киң җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итәргә батырчылык иткән барлык татар замандашларыннан бар яктан да аерылып торган шәхес[3]. Дәрдемәнд күп язмаган, көн үзәгендәге актуаль мәсьәләләр һәм шигарьләр аның иҗатында яңгыраш тапмаган, күпсанлы татар зыялылары кебек ул вакытлы матбугат битләрендә мәгариф, дин, милләт мәсьәләләренә багышланган иксез-чиксез бәхәсләрдә катнашмаган. Башка телләр йогынтысыннан азат булган «татар телен» дә лаф орып якламаган, тыныч кына үз ана телендә иҗат иткән. Шагыйрь кыска вакытлы уңышлар һәм тәрәккыять эйфориясенә дә бирелмәгән, шулай ук җәмгыятьтә тора-бара «җиңелүләр» нәтиҗәсендә формалашкан нигезсез торгынлык һәм пессимизм хисләре дә аны басып китмәгән. Дәрдемәнднең лирик иҗаты эчтәлеге һәм стиле белән, Галимҗан Ибраһимов әйтмешли, бер чуеннан коелган шикелле.

Шагыйрь исән чакта һәм узган гасырның 20-30 нчы елларында да татар тәнкыйтьчеләрен Дәрдемәнд лирикасының тоны, яңгырашы кызыктырган һәм шул ук вакытта ялгыштырган да [5-7]. Минемчә, Дәрдемәнднең чордаш тәнкыйтьчеләре дә, соңрак аның иҗаты хакында язучылар да бер принципиаль хата җибәргәннәр: алар фикеренчә, шәхеснең реаль тормышы һәм шагыйрь тарафыннан тудырылган хыялый дөнья арасында артык зур аерма юк, һич булмаса, алар бер-берсе белән бик тыгыз, турыдан-туры бәйләнештә торалар. Мондый караш татар әдәби тәнкыйтендә социализм чорында гына формалашмый, аны без инде 1905 нче елдан доминант караш дип та-

[3] Биредә бу тезиска чыгарма рәвешендә өч кешене генә атап булыр иде: тар мәгънәдә (шагыйрьләр арасында) – Сәгыйть Рәмиев (1880-1926), киңрәк мәгънәдә, ягъни зыялылар һәм язучылар арасында – Фатих Әмирхан (1886-1926) һәм Галимҗан Ибраһимов (1887-1938).

ный алабыз. Анын «дөреслеген» бер төркем шагыйрьләр, язучылар тормышы һәм иҗаты нигезендә раслаганнар. Мондый тәнкыйтьчеләр күзаллавынча, әдәбиятның, һичшиксез, иҗтимагый вазифасы бар; авторның җәмгыятьтән аерылырга хакы юк, ә, киресенчә, ул үз иҗатында чорның иң актуаль мәсьәләләрен күтәреп, көченнән килгәнчә, шул сорауларга җавап бирергә тиеш. Рус әдәбиятында мондый карашлар XIX йөзнең соңгы чирегендә киң таралган булган, электән үк аларны (А.Герцен, В.Белинский, Н.Добролюбов, Н.Чернышевский карашларын) яклаучылар да күп булган. Татар язучылары һәм, гомумән, зыялылары җәмгыять тормышы белән 1905 нче ел революциясеннән соң гына зуррак масштабта кызыксына һәм шөгыльләнә башлыйлар. Нәтиҗәдә, аларның күпчелеге Русия мохите татарның дине, мәдәнияте, икътисады өчен бик аз мөмкинлекләр бирә дигән фикергә килә. Алар үзгәрешләрнең зарурлыгын таныйлар һәм үзгәртүләр тормышка ашырылганнан соң, киләчәк хәзерге чынбарлыктан начаррак булмас дип өметләнгәннәр. Кадимчеләр «алтын үткән заманаларны» кайтарырга хыялланса, җәдитчеләр төркеме «яңарышка» өмет баглап яшәгән, ягъни көнбатыш, иң беренче нәүбәттә, рус тәрәккыяте казанышларын татар киләчәге өчен үзләштерү һәм файдалану максатын куйганнар.

Иҗтимагый җаваплылык тойгысы 1905 нче елдан соң татар җәмәгатьчелегенең киң катлауларын, бигрәк тә язучыларны һәм зыялыларны, мәдәният һәм әдәбият белән кызыксынучыларны чын мәгънәдә дәртләндерә. Прозаиклар, драматурглар, аеруча шагыйрьләр, җәмгыятьтәге җитешсезлекләрнең сәбәпләрен фаш итә торган һәм мәгарифне, халыкны сазлыктан чыгара торган бердәнбер чара рәвешендә күпсанлы әсәрләр иҗат итәләр. Алар фикеренчә, битарафлык – яңа уянып килгән, яңадан аягына баскан татар милләтен богауда тоткан иң зур куркыныч. 1905-1907 нче еллар арасында язучыларның күпчелеге, максатларыбыз тиздән тормышка ашачак дип ышанып, эйфория хисләренә бирелсәләр, 1908 нче елдан алып Беренче бөтендөнья сугышына кадәрге вакытта исә, бар теләкләребез чәлпәрәмә килде, алда бер яктылык күренми дип, тирән кайгы хисләренә чумалар. Ике хис тә – эйфория һәм кайгы, ахыр чиктә алар иҗатында тулы чагылыш таба. Татар шагыйрьләре, бигрәк тә милли шагыйрь буларак танылган Габдулла Тукай (1886-1913), милләтнең киләчәген идеал итеп күзалларга тырышалар, шул ук вакытта алар үзләре дә тулысынча диярлек реаль замана һәм аның хәрәкәте җимешләре булалар. Әдипләр өчен тормыш белән иҗат үзара үрелә.

Әмма Дәрдемәнд башка. Ул яшәгән һәм иҗат иткән, һәрхәлдә, Октябрь революциясе, гражданнар сугышы һәм большевистик режим урнашканчыга кадәрге вакыт шагыйрь өчен бернинди роль уйнамаган. Аның шигырьләре үзгәреш кичерә торган чынбарлык турында сөйләми, алар вакытны очсыз-кырыйсыз бер бөтен итеп кабул итә. Шуңа күрә Дәрдемәнд лирикасы вакытка буйсынмавы белән үзенә җәлеп итә. Сибгат Хәким сүзләренчә: «Дәрдемәнд миллион еллар, мәңгелек белән эш итә» [8: 8]. Дәрдемәнд бәяләми, аның урынына ул турыдан-туры күзгә ташланмый торган хакыйкатьне сүз-сурәтләр ярдәмендә тасвирларга тырыша һәм шул сүзләрдән күренешләр туа, музыка яңгырый кебек. Аның шигырьләре метафоралар белән тулмаса да, гаҗәеп бер моңга, хәтта кырысрак булган матурлыкка ия. Дәрдемәнд шигърияте, рус символисты Вячеслав Иванов сүзләренчә, «турылана торган спираль хәрәкәтен биргән» энергия кебек кабул иткән, күрәсең.

Алга таба мин шушы гомуми характеристиканы Дәрдемәнд иҗатыннан[4] мисаллар китереп конкретлаштырырга булдым. Шул уңайдан Дәрдемәнд иҗатын аерым төп темаларга бүлеп тасвирларга тырыштым. Димәк, биредә шагыйрь лирикасы өчен хас булган иң әһәмиятле тема-мәсьәләләр китерелгән. Бер яктан, алар Дәрдемәнднең «мәңгелек темалар» («дөнья үз-үзеннән») белән кызыксынуын, икенче яктан, аның үз чоры һәм тормышы мохитен, традицияләрен («ватан»)

[4] Вафатына кадәр (9 нчы октябрь 1921 нче ел) Дәрдемәнднең бер генә шигырь китабы да дөнья күрми. Бәлки, монысын ул үзе теләмәгәндер, бәлки башка сәбәпләр аркасында бастыручыларга рөхсәт бирмәгәндер. 1929 нчы елда Исмәгыйль Рәми, беренчеләрдән булып, Дәрдемәнд шигъри мирасын туплап, аларны бер җыентык формасында чыгара [1]. Рәис Даутов редакциясендә 1980 нче елда Дәрдемәнд шигырьләренең иң тулы җыентыгы дөнья күрә [9]. Бу ике басма минем өчен төп чыганак булып торды. (*М.Фридерих мәкаләсендә шигырьләрнең текстын 1929 нчы ел басмасыннан китерсә дә, мин шул ук шигырьләрдән цитата биргән вакытта укучыбызга танышрак булган 1980 нче ел басмасына таяндым һәм искәрмәләрдә бу басманы күрсәттем – Тәрҗемәче искәрмәсе*).

бик тирәнтен аңлавын һәм бу мотивларның шагыйрь иҗатында яңгыраш табуын исбатлый.

Дәрдемәнд иҗаты – үз чорында һәм дистәләгән еллар соң да, әдәби-эстетик кыйммәтен югалтмый торган мирас. Бу кыйммәтне әсәрләр язылган чорның иҗтимагый, сәяси шартларын, хәтта шагыйрьнең шәхесен белмәсәң дә танышың. Бу иҗат үзеннән-үзе бер даимилек буларак яши. Дәрдемәнд шигърияте укучы игътибарын үзенә эчтәлеге белән генә җәлеп итми, ә форма һәм тел ягыннан да югары сыйфатка ия, татар әдәбиятында ул чорда да, соңрак та аңа тиңләрлек шигырьләр юк. Шул сәбәпле, аларны алман яки башка Европа телләренә тәрҗемә итү бик авыр. Дәрдемәнд шигырьләренең формаль бүленешен һәм эчтәлеген укучыга җиткерү максаты белән, минем тарафтан аларны алман теленә тәрҗемә итү омтылышы ясалды.

Шагыйрь Дәрдемәнд өчен *табигать* бик зур әһәмияткә ия: бу сыйфат табигатьне үз сүзләре белән сөйләткән шигырьләр санында да күренә. Дәрдемәнд табигатькә дан җырламый, ул аны аңлатмый да, аңа гаҗәпләнми дә. Ул табигатьне тыңлый белә, табигатьне күрә белә. Аның шигырьләрендә укучы һәм тыңлаучы белән әңгәмә алып бара торган табигать бакчалар һәм ихаталар белән тулган «ясалма табигать» түгел, ә бәлки Закир Рәмиев үзе күргән Көньяк Урал тауларының, Орск, Оренбург, Уральск тирәләрендәге чиксез даланың «табигый табигате». Дәрдемәнд кабул иткән табигатьтә, шагыйрьнең лирик героен искә алмасак, кешегә урын юк – ул аның өлеше түгел, ул аның өчен чит («Ятам кай чаклары моңлап... » [9: 80]).

Дәрдемәнд җәйне тасвирламый. Ул аның өчен бары тик узганнарга бәя бирү чарасы гына. Җәйнең үз сыйфатлары юк, шуңа да карамастан, җәй аннан соң килә торган фасылга караганда ягымлырак һәм матуррак («Җәй үтте…» [9: 93]). Шагыйрь үз иҗатында кыш фасылына күбрәк игътибар итә, әмма кыш аның өчен җансыз, һәм узган гомернең символы булып килә («Кыш көннәре» [9: 51])[5].

Татар тәнкыйтьчеләре Дәрдемәнднең дөньяга карашын пейзаж лирикасы шигырьләренә таянып бәяләргә тырыштылар, һич булмаса, аларда шул карашның кайтавазын эзләп карадылар [10: 207-208]. Бу ноктадан караганда, әлеге тәнкыйтьчеләр шикелле, кышның хәрәкәтсезлеген һәм җансызлыгын тасвирлаган Дәрдемәнд фикерендә һәм эшендә төп мотив итеп, чыннан да, «өметсезлек»не билгеләп була. Дәрдемәнд кышны да, җәйне дә сөймәгән һәм, минемчә, моның сәбәбе түбәндәгедән гыйбарәт: бу фасылларның икесе дә статик, алар өчен тиз чәчәк ату да, шулай ук тиз сулу да хас түгел. Дәрдемәндкә исә хәрәкәтчәнлек бик якын – нииндидер максатка омтылыш хәлендә генә түгел, ә үзеннән-үзе туктаусыз хәрәкәт процессы. Хәрәкәтнең тәмамлануы яңа башлангычны аңлата, ә ул язучы күңеленә якын. Шуна күрә дә шагыйрь бөтен җаны белән язны сөя, аның каләме тарафыннан язга багышланган бер шәлкем шигырьләр язылган. Яз үз матурлыгы белән кыш фасылыннан күпкә өстен [1: 67-68].

Көлемсерәп көн башланды,  
Җәйге күркәм таң белән,  
Япраккайлар да яшьләнде,  
Һәм тибрәнде яшь үлән [1: 69].

Яки менә тагын Дәрдемәнд өчен һич типик булмаган, эйфорик рухта язылган юллар! Болар хәтта шигырьгә дә охшамаган, алар күбрәк кинәт туган хисләр чагылышын хәтерләтә:

Бу ул матур, бу ул күркәм, бу ул,  
Бу ул – хуш исле яз!  
Бу ул – хуш исле таң җиле! [9: 134].

Дәрдемәнднең «табигать шигырьләрендә» зур ишарәләр дә, купшы бизәкләр дә юк. Аларда шагыйрь табигатьнең гайре табигый күренешләрен тасвирламый, хәтта «табигатьнең көндәлек тормышын» тел яисә формаль экстравагантлык аша күрсәтеп, укучыны кызыктырмый, көчерелмә мәгънәдәге образлар аша табигатьне аңлатырга тырышмый – табигать биредә үзе сөйләгән кебек тоела. Дәрдемәнд шигырьләре сүзнең иң позитив мәгънәсендә «гади» һәм шул гадилек аркылы алардан тынычлык хисе бөркелеп тора шикелле. Бу тынычлыкта табигатьнең ябык, серле яшәеше чагыла – Дәрдемәнднең калебе дә шундый халәттә дип фаразларга була һәм ул табигатькә колак сала («Болыт үтте... » [9: 132]).

Дәрдемәнднең табигате җирле чикләргә ия: ул *ватан* өлеше, шул ватанда кешеләр яши, *халык* яши. Икесе дә – ватан һәм халык – шагыйрь Дәрдемәндкә дә, шәхес Закир Рәмиевкә дә бик якын. Ләкин Закир әфәнде 1910 нчы еллар ахыры вәсвәсәләренә кадәр, зур уңышсызлыкларга очрамыйча, армый-талмый халкы һәм ватаны иминлеге өчен бөтен көчен

[5] Бу шигырьне «Кышкы төн» шигыре белән дә чагыштырып була. Соңгысын Дәрдемәнд А.С.Пушкинның «Зимний вечер» шигыренә ияреп язган [9: 29-30].

салса, аның шигъри alter ego сы ватанның һәм халыкның киләчәгенә скепсис белән карый. Мондый эчтәлектәге әсәрләрендә автор-Дәрдемәнд, актив катнашучы буларак түгел, ә бәлки ияреп баручы, кайвакыт зарланучы, сыкранучы, читтән күзәтеп торучы буларак гәүдәләнә («Әгәр барсаң, саба җил, безнең илгә» [9: 91]).

Дәрдемәнд «халкын» һәм «туган ягын» читтән күзәтеп тора. Ул «ватанына» һәм «халкына» якынаерга да ашыкмый, ә «саба җилен» җибәрә, аның «туган илгә, нечкә билгә» сәламнәр тапшыруын үтенә. Бу хәлне ике төрле аңлап була: яисә шагыйрь туган илендә, халкы арасында түгел, яисә ул үзе «саба җиле» вазифасын үтәргә теләми яки хәтта үтәрлек хәлдә түгел. Шунысы да күренә: Дәрдемәнд, ватанына, халкына якынаерга теләмичә, алар белән саубуллаша, ә саубуллашу һәм урынга, һәм вакытка карый. Туган илен һәм халкын шагыйрь ерактан сәламли һәм сәламнәрен чынбарлыкка түгел, ә үзенә бәхетлерәк булып тоелган чорга, узганнарга юнәлтә («Видагъ» [9: 90]).

«Кораб» (1908) исемендәге иң атаклы шигырендә Дәрдемәнд ватанының чынбарлыгын тасвирлый [9: 36]. Иге-чиге күренмәгән, рәхимсез диңгез уртасында кечкенә генә көчсез кораб, дулкыннар аны капларга гына тора, җил котырына! Бер генә татар шагыйре дә, минемчә, беренче рус революциясеннән соң илдә хөкем сөргән билгесезлекне тасвирлау өчен мондый сүз-сурәтләр таба алмаган. Нәрсә буласы билгесез, киләчәктә кешелекне нәрсә көтә – билгесез… Татарлар өчен генә түгел, империядәге һәрбер милләт вәкилләренә киләчәк нәрсә әзерләгән? Кешеләргә бары тик шунысы ачык: узганнар инде кабатланмас, ә бүгенге көн – ул бер күчеш чоры, ләкин аның кая алып барасын беркем белми.

Менә шул билгесезлектә Дәрдемәнд ачыклык эзли. Кайвакытта шагыйрь аңа ирешкән кебек тә тоела. Ул елларда мондый ачыклыкны аңа милләттәшләре биргән:

Ни газизрәк – бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мокаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр! («Гөрләгән сулар башында…» [9: 92]).

Шигырьдә автор тарафыннан, сәяси яктан билгеләнеп, административ чикләргә ия булган урынның туган ил, ватан түгеллеге хакында фикер үткәрелә. Кала торган нәрсә – биредә туган һәм яши торган кешеләр, алар ата-бабаларының дан-шөһрәтләрен истә тоталар, шуларны буыннан-буынга тапшырып киләләр. Бу шигырендә Дәрдемәнд үзе һәм «халкына» булган мөнәсәбәте турында сөйли[6]. Шул ук вакытта, минем өчен шунысы да көн кебек ачык: Дәрдемәнд «татар» милләтчесе яисә расист түгел. Ул үз халкы белән горурлана, аңа тирән ышанычын белдерә, шул ук вакытта, татар халкының барлык сыйфатларын таныган хәлдә, башка халыкларның да, кайда, нинди мохиттә яшәсәләр дә, шундый ук үзенчәлекләргә ия булу хокукын таный. Димәк, Дәрдемәнднең өметен «идеал дөнья-ватан» дип атап булыр иде.

*Кешенең бу дөньяда тоткан урыны* мәсьәләсе Дәрдемәнд иҗатының үзәгендә тора. Бу мәсьәлә, әлбәттә, үтә яңа түгел – «дөнья» әдәбиятында да, «татар» әдәбиятында да аны «мәңгелек темалар» рәтенә кертеп була. Бу темага кагылышлы ике аспект та Дәрдемәнд иҗатында чагылыш таба – абстракт кеше-индивидуумга мөнәсәбәт («кеше үз үзендә», «человек в себе»); конкрет индивидуумның, ягъни лирик геройның яисә шагыйрьнең кеше буларак үзенең тарихи, җирле яки социаль мохитенә мөнәсәбәте.

Башка шагыйрьләр лирикасындагы кебек үк Дәрдемәнд шигъриятендә дә бу ике аспектны төгәл аеру һәрбер очракта да мөмкин түгел. Аның кайбер шигырьләре шул кадәр йомгакланган тирән фикер белдерүгә корылган, аларны хәтта тотрыклы образлы гыйбарә, афоризм итеп кабул итәргә мөмкин. Аларның мәгънәсен ниндидер аерым бер тон белән генә аңлатып булмый, аларны конкрет шагыйрь Дәрдемәнднең дөньяга карашын тикшергәндә, бертөрле генә темага ялгап та булмый. Фикеребезне өч мисал белән раслап була:

| | |
|---|---|
| 1) Түгел лаек яманлык яхшыларга | 3) Бүген уйнап-көлүдән тыйма, зинһар. |

[6] Шагыйрь «халык»ны «милләт» дип түгел, ә «кавем» дип атый. Монысы да очраклы түгелдер, чөнки «милләт» сүзе беренче рус революциясе елларында «мода»га кереп, ачык сәяси эчтәлеккә ия була. Ул (теләнгән) чынбарлыкка һәм киләчәккә барып тоташа, һәм шулай ук Көнбатыш Европада кабул ителгән «nation» концепциясен татарчалаштырырга яки татарга якынайтырга омтылыш дип бәяләргә мөмкин. «Кавем» төшенчәсе исә, бернинди сәяси эчтәлеккә ия түгел, кешенең этник үзаңына кайтып кала, аны килеп чыгышы һәм үткән заманнар белән тоташтыра.

Ярамасларга яхшылык ярамас
[9: 162].
2) Әгәр йөз напәсәнд эш кыйлса дәрвиш
Йөз иптәшнең бер-бере алмый телгә;
Вә гәр бер напәсәнд эш кыйлса солтан,
Аның даны очадыр илдән-илгә
[9: 59].

Үләргә көн булыр – алда әҗәл бар!
Тыя күрмә – уен уйнар мәлендә,
Әҗәл эшләр эшен үз тәңгәлендә!
[9: 108].

Минемчә, башкачарак бер фикер түбәндәге юлларда яңгырый:

Күңел һәр җирдә гөл эзли,
Кадәр һәр жирдә тикән төзли…[9: 148].

Бу икеюллыкның эчтәлегенә ниндидер гомумилек хас булса да, ул барыбер Дәрдемәнднең лирик «мин» яңгыраган шигырьләрен хәтерләтә. «Мин» яки «без» формасында булса да, шагыйрьнең лирик «мин»е бик киң күләмле, киң офыклы – ул аерым бер шәхес белән генә бәйле түгел, гүя ул бөтен кешелек хәяте белән бәйле. Шул ук вакытта ике формадагы «мин» үзенең төп үзенчәлеген саклап кала: ул киләчәккә генә түгел, бәлки бүгенге көнгә дә өметсез карый, аңа күңел төшенкелеге, кәефсезлек, ышанычсызлык хисләре хас («Гомерләрдер…» [9: 137], «Ничә багълар күңелләрдә төзелде... » [9: 70]).

Күренә ки: «мин» нинди формада гына булмасын, узганнарга ул барыбер өметсезлек белән карый, узганнар нинди генә булмасын, киләчәктә дә язмышка каршы тору мөмкин түгеллеге раслана. «Шура» журналының 1910 нчы ел 21 нче февралендә басылган «Без» шигыре бу фикергә иң яхшы мисал булып тора [9: 38].

Дәрдемәнд көнчыгыш шигъриятендә киң кулланылган *кеше – кунак* мотивына мөрәҗәгать итә. Кеше бу дөньяда бары тик кунак кына, шуна күрә аның сөякләре моңа кадәр җир астына тезелгән кеше сөякләренә кушылып кына бара, аның да эзләре мәңгелек комы белән күмелә. Бу «уен» очсыз-кырыйсыз спиральне хәтерләтә: «иске»нең бетүе шул ук вакытта «яңа»ның башлануын аңлата.

Дәрдемәнднең лирик «мин»е дөньяның, язмышның рәхимсезлегенә тулысынча буйсынмаган. Кайвакыт аның шигырьләрендә тормышка өмет, ышаныч та чагыла. Тарихи барышны үзгәртеп, туктатып булмаса да, аңа теләк булганда ияләшергә мөмкин («Нәсыйхәт» [9: 72]). Беренче карашка, бу әсәрдә шагыйрь кешеләрне дөньяда тулы канлы тормыш алып барырга, вакыйгаларның барышына бирешмәскә, ә, киресенчә, аларны үз кулыңа алырга, үзеңне көчсез итеп хис итмәскә, үз ихтыярың кушканча эш итәргә өнди. Ләкин, минемчә, шул ук юлларның ачы, сарказмлы яңгырашы бу беренче карашка туган фәлсәфи фикерне юкка чыгара. Закир Рәмиев игътибарсыз, ихтирамсыз кеше һәм эшкуар булмаган шикелле, шагыйрь Дәрдемәнд декадент шагыйрь түгел. Бу шигырьдә шагыйрьнең тормыш, яшәеш хакындагы фикерләре генә түгел, ә шул чор иҗтимагый мәнфәгатьләрен үз дәрәҗәләренә лаек булмаган югарылыкта бәяләү фәлсәфәсенә мөнәсәбәте чагылыш тапкан. Көчлерәкләр алга узалар, ә көчсезләр артта кала баралар. Дәрдемәнд үзен шул көчсезләр сафында күргән, дөнья андыйларны танымаган, бәяләмәгән. Бу сыйфат лирик «мин»кичерешләрен сурәтләгән күңел лирикасы әсәрләрендә ачык чагыла («Бүзләрем мана алмадым... » [9: 48-50]). Бу шигырьдә лирик геройның өмет өзелү, үкенү, хәтта әрнү, хисләре гәүдәләнә. Шигырьләрдә шунысы да ачык күренә: татар тәнкыйтьчеләре мәкаләләрендә башкачарак бәя-хөкемнәр яңгыраса да, шагыйрь үзе төзегән иҗат сараенда тормыш итү белән генә канәгатьләнми[7]. Дәрдемәнд дә танылуга мохтаҗ, ләкин ул замана белән үзгәрә торган зәвыкка үз шигырьләрен яраклаштырырга теләми.

Тиешле дәрәҗәдә танылмаумы, әллә хаксызга гаеп ташлауларның чамадан артып китүеме, шагыйрьнең тирә-якка һәм үз-үзенә мөнәсәбәтен үткенәйтеп җибәрәләр. Бу уңайдан Дәрдемәнд гаять дәрәҗәдә кыска, үткен, төгәл һәм халыкчан булган шигъри афоризмнар – хикмәтләр иҗат итә («Күңелемнең әзрәк кенә кинәсе бар...» [9: 149]). Инә детале аша автор тәрәккый идеясе һәм милли эйфория хисләре белән артык мавыккан замандашларына үзенең ироник мөнәсәбәтен белдерә. Мәсәлән, 1905 нче елгы инкыйлаб дулкыны белән татар галәмендә баш калкыткан күпсанлы шагыйрьләргә һәм басылган бихисап шигырьләргә бәя бирү максатыннан, шушы алымнан файдалана («Мөгзе бар куйның бары да кучкар түгел... » [9: 116].

Кавем күңелендә яңа уянган һәм вакыты белән чамадан тыш игътибар бирелгән татар милли хисе, «татарлык» белән артык горурлану

[7] Кара, мәсәлән: [11].

Дәрдемәнд өчен бер химера булып тора. Татар милли үзаңын формалаштыруга тырышуларның, татар милләтен нигезсез күккә чөюләрнең, мактауларның көлкегә әверелү мөмкинлеген Дәрдемәнд «татар» этнонимы мисалында күрсәтә («Хәялдан сүз ачып, берничә галим.... » [9: 88].

Дәрдемәнд аерым бер дүртьюллыкларында, русча яшәү үрнәгенә омтылып, милли чынбарлыкка тулаем тискәре мөнәсәбәттә булган ялган укымышлыларны да тәнкыйтьләли («Ышкульникка» [9: 41]).

Агулы инә шагыйрьнең үзен дә кызганмый. Лирик «мин»нең гомумиләштерелгән «без»е икенче планга күчә һәм аның урынына «мин» калкып чыга. Лирик «мин» кичерешләрен һәм халәтен тасвирлаган сүзләр үзләренең ачыклыгы һәм үткенлеге белән аерылып тора. Бу үзгәрешнең сәбәбе шагыйрьнең танылып җитмәве белән генә билгеләнми. Аны заман үзгәрешеннән, кырыслыгыннан да эзләргә кирәктер: ачлык, тиф эпидемиясе, Беренче бөтендөнья сугышы, Февраль, ә аннан соң Октябрь революциясе, гражданнар сугышы – Закир Рәмиев тормышында эзсез үтә алмаган шикелле, алар шагыйрь Дәрдемәнд иҗатына да көчле тәэсир иткәннәр.

Искелек белән яңалык арасында көрәш гаҗәеп дәрәҗәдә кискенләшкән 1910 нчы еллар ахырында, Дәрдемәндне иң куркыткан нәрсә – искелекне югалту яки аның урынына килгән ниндидер яңа, ят нәрсә түгел, ә шушы каршы яклар арасындагы каршылыкның чишелү формасы. Кискенлек, яңа җәмгыять төзүгә куелган чиксез ихтыяр көче, хакимияткә омтылыш – шагыйрь тарафыннан кабул ителә алмый торган чит күренешләр. Ул аларга нәфрәт белән карый, үзенең көчсезлеге аны сокландыра («Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан...» [9: 110]).

Көчсезлек бәхетенең шәхси тынычлык һәм ирек гарантиясе булып торуына шагыйрь, күрәсең, ышанган яки, һич булмаса, өметләнгән. Күпмәгънәлекнең замана рухына туры килмәгәнлеген ул төшенә. Киләчәкнең чынбарлыгы ачыклык таләп итә һәм Дәрдемәнд кушылырлык бердәнбер шигъри ачыклык – ул дәшмәү («Җитәр инде, Дәрдемәнд, сүзне озатма...» [9: 140]). Шагыйрь дәшми торучыларның урынын төгәл белә («Куанды ил, канат какты мәләкләр...» [9: 89]. Шагыйрь Дәрдемәнднең иҗат дәрте тибеп торган каләме шул рәвешле язудан туктарга мәҗбүр була. Закир Рәмиев 1921 елның 9 октябрендә Орск шәһәрендә дөнья куя. Ул мәңгелеккә киткән йортның тәрәзәләре Урал елгасына карыйлар. Козгыннар да очудан туктый һәм аның туган иле хәзер инде шагыйрьсез яшәргә тиеш була.

XX гасыр башы татар шигърияте өчен Дәрдемәнд шигырьләре – уникаль, кабатланмас күренеш. Бу чор лирикасында, бер шагыйрьдән башка, аның белән янәшә куярлык исемнәр юк. Сәгыйть Рәмиев (1880-1926) иҗаты гына Дәрдемәнднеке шикелле үк мөстәкыйль һәм аерым урында тора. Әдәби мирасларының мәгънәви эчтәлегендә чагылган «дөньяга карашларында», өлешчә тел-стильләрендә һәм шигъри формаларында бу ике шагыйрьнең үзенчәлекләре билгеләнә. Алар әдәбият-сәнгатьнең иҗтимагый вазифасын татар халкы үсешенә һәм яңарышына хезмәт итүдә таныган татар шагыйрьләреннән, язучыларыннан, зыялыларыннан әлеге карашны кабул итмәүләре белән аерылып торалар. Шулай да Дәрдемәнд һәм Сәгыйть Рәмиев лирикасында шагыйрь мотивы, шагыйрьлек миссиясе проблемасы үзәктә тора: шагыйрь – үз иҗатында дөньяга мөнәсәбәтне, яшәеш серләрен, иҗтимагый хәрәкәтне һәм тарихи барышны аңлата торган зат. Бу төп ышаныч ике шагыйрь өчен дә уртак. Дөньяны һәм анда кеше урынын аңлауда бу ике шагыйрьнең бәя-хөкемнәре бер-берсеннән аерыла. Дәрдемәнд шигырьләре фикри-мәгънәви яктан гаҗәп дәрәҗәдә тыгыз, алардагы тасвирлар һәм образлар бер-берсенә бәйләнгән, музыкаль яңгырашлы, күләмнәре зур түгел. Шигъриятенең бу сыйфаты шагыйрьнең кеше хакындагы фәлсәфи гаменә тулысынча туры килә: кеше – вакыт һәм киңлек ягыннан чикләнмәгән галәмнең бик кечкенә һәм тиз үтеп китә торган кыйпылчыгы. Сәгыйть Рәмиев шигырьләре исә – ул экстатик кычкыру, алар сызгырган камчы тавышын, күк күкрәүне яки ачулы, ироник көлүне хәтерләтәләр. Аларда – көчле, гыйсъян рухлы, шәхси хөрлегә бер нәрсә белән дә чикләнмәгән, тормышка ябышып яткан, үлемгә дә бирешмәгән «Мин»[8]. Мисалга «Кабакта мәхәббәт» [14: 32-33][9].

[8] 1920 нче еллар башындагы «ультра-сул» интеллектуаллардан башлап, 1960 еллар ахырына кадәр совет әдәбият белгечләре Сәгыйть Рәмиевне кискен тәнкыйтьлиләр. Аны «агностицизмның» типик вәкиле дип атап, «анархо-индивидуалистлык» вәкиле буларак фаш итәләр һәм «татар Есенины» дип хурлыйлар. Кара: [12].

[9] 1913 нче елның язында татар милли шагыйре Габдулла Тукай «Кыйтга» дигән шигырен яза [13].

Татар мохитеннән читкәрәк китеп, шул чор төрки-тугандаш Урта Азия халыклары лирикасында охшашлыклар һәм Дәрдемәнд шигърияте белән параллельләр эзли башласак, минемчә, бары тик бер шагыйрь иҗатында гына шундый охшашлыклар күзәтелә. Ул – 1897 нче елда Әндиҗанда, Фирганә үзәнендә туган Габделхәмид Сөләйман шигърияте. «Чулпан» псевдонимы белән язган бу үзбәк шагыйре «XX йөз үзбәк лирикасы, драматургиясе, прозасында хәлиткеч роль уйнаган»[10]. Дәрдемәнд шикелле үк Чулпан да үз шигырьләрен гади телдә яза һәм нәкъ шул гадилек аларны аерата тәэсирле һәм мәгънәле итә. Әмма бу ике шагыйрьне тел мөмкинлекләрен уңышлы файдалану гына якынайтмый, алар сайлаган мотивлар һәм метафораларда да параллельләр ачык күренә. Чулпан шигырьләрендә дә табигатькә, ел фасылларына зур идея-эстетик вазифа йөкләнә, һәр икесе дә кышкы табигатькә битараф: Дәрдемәнд шигъриятендәге кебек, Чулпан иҗатында да карга бәхетсезлек, кайгы, куркыныч, начарлык мәгънәләрен символлаштыра [15: 414, 424, 448, 482, 508, 511]. Минем уйлавымча, Чулпан шигырьләрендә сәяси мотивлар һәм интерпретацияләр Дәрдемәнднекенә караганда ачыграк күренсә дә, ике шагыйрьнең «дөньяга караш»ларында охшашлык бар. Дәрдемәндтәге тормыш башлангычының һәм гомер агышының дәвамлы бер әйләнеш буларак кабул ителеше Чулпан иҗатында да күзәтелә. Чулпан фәлсәфәсенең дә сурәтле формасы – табигать символикасында. Бу сыйфат шагыйрьнең 1926 нчы елда иҗат ителгән «Бәһарны сагындым» дип исемләнгән шигырендә чагылыш таба: көз җитте, кыш ишек кага, агачлардагы яфраклар саргая һәм коела башлыйлар, тереклек үлемгә йөз тота. Әсәрдә шагыйрь тавышы ишетелә:

Юк... Үлем юктыр!
Бары бер яну, бер сүнү бардыр.
Бер янып, сүнеп... Яңадан яну бар.
Яңа язлар,
Яңа лаләләр,
Яңа сез, әй, иркен теләкләр! [15: 522][11].

Ачык, гади тел, ирекле форма белән «көнчыгыш зирәклеген»ең уңышлы синтезына ирешү юлында Чулпанга Дәрдемәнд кенә түгел, ә һинд шагыйре Рабиндранат Тагор да үрнәк булган.

Классик Һиндстан һәм Иран фәлсәфи-мистик шигъриятен дәрт чыганагы буларак артык якын итмәгән Русия империясе төрки телле шагыйрьләреннән аермалы буларак, XIX йөз уртасында Көнбатыш шагыйрьләре яңа «Көнчыгыш» дөньясын һәм аның шигъриятен ача башлыйлар [16]. Көнбатыш әдәбиятында Дәрдемәнд белән янәшә куярдай бары тик бер шагыйрьгә игътибар итәсем килә: әсәрләренең теле, шигъриятне аңлавы, «миндәге дөньяга» (мир в себе) карашы бу шагыйрьне, һичшиксез, Дәрдемәндкә якын итә. Ул – Уолт Уитмен. «Көнчыгыш», шул исәптән Дәрдемәнд белән «Көнбатыш» шагыйре Уитмен арасындагы күпер бер дә Уитмен белән Тагор арасындагы күпердән тар түгел. Ул үз-үзен еш кына «Көнчыгыш һәм Көнбатыш арасында күпер» итеп билгеләгән һәм үзеннән башка бер Америка шагыйре дә Көнчыгышның мистик рухын шулай яхшы аңламый дип ышанган [17: 396]. Чыннан да, әгәр без бу Америка шагыйренең үз иҗаты турындагы сүзләрен алсак, алар турыдан-туры Дәрдемәнд шигърияте хакында әйтелгән кебек тоелалар: «Бөтен яшәгән нәрсә – синдә, бездә, барыбызда, ул безнең барыбызда да бар: кешеләрдә, заманаларда, хайваннарда, үсемлекләрдә, ташларда. Без – ул бар нәрсә һәм бар нәрсә – ул без. Башлангыч һәм ахыр, туу һәм үлем – алар нәрсәләр соң? Бар нәрсә – ул мәңгелек хәрәкәт. Ашкыну, омтылыш, дәрт. Дөньяны тудыручы мәңгелек теләк». Бу сүзләр белән Иоһаннес Шлаф 1892 нче елда Уолт Уитмен һәм аның «Үлән яфраклары» исемле төп әсәрен бәяли [18: 181]. 1907 елда Густав Ландауэр шулай дип язган: «Уитмэн шигъриятенең иң әһәмиятле ягы: ул фикер йөртергә өнди, укучы өчен аның образлары һәрвакыт әзер – алар дулкын кебек уйныйлар, я якынаялар, я ерагаялар» [18: 192]. 1857 нче елда басылып чыгып, поэзиянең асылын аңлауга багышланган «Демократик мөмкинлекләр» дип аталган эсседа Уитмен үзе дә нәкъ менә шул «ышандыру»ны, фикер йөртергә өндәүне чын шигъриятнең әһәмиятле һәм зарури билгесе дип аңлата: «Кеше фикере, шигърият яки мелодия ачык булмаса да, котылу

---

һәм анда өметсезлек, бигрәк тә үз иҗатыннан канәгатьсезлек хисләре белдерелә. Бу шигырьнең соңгы икеюллыгы: «Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш». Минем уйлавымча, Сәгыйть Рәмиевнең “Мин” шигыре Тукай сүзләренә сатирик бер реплика буларак кабул ителергә мөмкин.

[10] Ингеборг Бальдауфның әлегә басылып чыкмаган «Чулпон» дип аталган мәкаләсеннән.

[11] Үзбәкчәдән татарчага ирекле тәрҗемә. – *Тәрҗемәче искәрмәсе.*

юлларын күрсәтергә тиешләр, аларның характеры киңлеккә якын йомшак, нәфис булырга тиеш. Хыяллана белмәгән кеше фикерне аңлый алмаса да, ул барыбер югары максатка ирешү өчен зарури» [19: 49-50]. Башка бер урында: «Берәр теманы яки фикерне мин мөмкин кадәр аз ачарга яки күз алдына китерергә һәм сезне, укучым, шул тема яки фикер атмосферасына кертергә, үз очышыгыз белән очыртырга тырышам» [20: 44-45].

Каршына шундый максатны куйган шагыйрь бик үткен күзле һәм хисле күзәтүче булырга тиеш. Бар дөньяны, тирә-якны, галәмнең барлык матди һәм рухи күренешләрен ул бөтен күңеле белән кабул итәргә тиеш. Уитмен үзе шундый шагыйрь булган, Дәрдемәнд дә шундый. «Сәлам, дөнья!» дигән шигырендә Уитмен бар дөньяны кочып ала: «Нәрсә ишетәсең син, Уолт Уитмен? (...) Мин Сүриядәге чикерткәләр черелдәвен ишетәм. (...) Мәчет башыннан гарәп мөәзиненең тавышын ишетәм. (...) Мин казакларның кычкыруын, Охотск янындагы диңгездә матрослар тавышын ишетәм. (...) Нәрсә күрәсең син, Уолт Уитмен? (...) Мин ут белән караңгылыкның кинәт кенә алмашуын күрәм. (...) Ачык итеп, мин Гималай, Тянь-Шань, Алтай тауларын күзәтәм. (...) Азия даласын күрәм. Монгол тирмәләрен, калмык һәм башкорт тирмәләрен күрәм. (...) Мин үткен күзле самоед һәм финнарны күрәм. (...) Мин бар җир шарын күрәм һәм бернинди аермасыз мин алар белән бергә. (...) Һәм мин җирдә яшәүче барлык кешеләрне сәламлим. Сәлам, дөнья! Кайсы шәһәрләргә яктылык һәм җылылык барып ирешә, мин дә шул шәһәрләргә юл тотам! Кошлар оча торган барлык утрауларга да мин дә очып барам (...)» [21: 130-142][12].

Бу очышны җиңеләйткән һәм мөмкин иткән иң мөһим чара – ул тел, әгәр дә шагыйрь укучының, бәлки дөресрәге, тыңлаучының йөрәгенә тизрәк барып җитәм ди икән – тавыш һәм яңгыраш бик зур роль уйныйлар. Дәрдемәнд һәм Уитмен – тел осталары. Бу ике шагыйрьнең дә теле – югары дәрәҗәдәге ритм һәм рифмадан, ассонанс һәм аллитерациядән, сүзләр һәм җөмләләр тезелүендә, сүзләрнең бер-берсен төрле темпта алмаштыруыннан, алар арасындагы цезуралардан һәм паузалардан тора. Бер яктан караганда, икесе дә «гади», көнкүрештә сөйләшә торган телдә иҗат итәләр, ләкин, икенче яктан, стиль, сүз сайлау ягын алсак, телләре борынгы прозаны хәтерләтә (Рэчел Полонски [22: 409-410]). Бернис Слот аларның телен «борынгы телнең бер төре» (a kind of earth-language) дип атый [23: 236]. Әлеге характеристикадан без телне «җиргә бәйле» итеп танысак, ягъни җирдә туган, җирдә тамырланган тел, икенче яктан, без аны «җирне кочарлык» хәлдә булган тел итеп кабул итә алабыз, башкача әйткәндә, бөтен җирдә танылырлык, кабул ителерлек тел. Минем уйлавымча, мондый бәя Дәрдемәнд һәм Уолт Уитмен иҗатларына бер дәрәҗәдә туры килә.

XIX йөз ахырында Русиянең күп кенә зыялылары, язучылары, шагыйрьләре яңа офыклар, шул офыкларга алып бара торган юллар эзләү белән мәшгуль булалар. Бу эзләнүләрнең төп юнәлеше – Көнбатыш[13], яңалыкка сусауны басарга ярдәм итә торган чишмә – Уолт Уитмен иде: «XIX йөз рус мәдәнияте тарихында Уолт Уитмен ролен бик югары бәяләргә кирәк. Аның аудиториясе, аңа хөрмәт, аның йогынтысы гаҗәп зур була» [25: 300]. Рус шагыйрьләре, бу эзләнүләрнең төп максаты итеп, «поэзиянең мәңгелек образын реабилитацияләүдә» күргәннәр [26: 10]. 1906-1908 нче еллар әдәбиятында рус символистларының идеологы булган Дмитрий Мережковский шагыйрьләрнең «баналь» трагикадан китә алмауларын һәм актуаль темаларга карата сукыр булып калуларын фаш итә һәм сәнгатьнең әхлакый түгел, ә эстетик проблема икәнлеген яклап чыга: «Сәнгатьнең иң югары әхлакый максаты нинди әхлакый тенденцияләрне чагылдыру түгел, ул сәнгатьченең хакыйкатькә риясыз, сатылмас һәм тугрылыклы мәхәбәттеннән, аның бер нәрсә белән дә чикләнмәгән риясызлыгыннан тора» [26: 11]. Валерий Брюсов, 1894 нче елда чыккан «Русские символисты» дигән җыентыкның кереш сүзендә болай дип яза: «Символизмның максаты – бер-бер артлы алмашынып тора торган күренешләр аша укучыны гипноз хәленә кертү, үзенә күрә аның рухын үзгәртү» [27: 16]. Шуңа күрә, В.Брюсов фикеренчә, шагыйрь өчен иң әһәмиятлесе – «дөнья күренешләре һәм әйберләре өчен дөрес исемнәр табу» [27: 50]. Бу «исемнәр» ягъни «символлар», Вячеслав Иванов карашынча,

[12] Биредә мин ирекле рәвештә Дәрдемәнд иҗатына географик яки мәдәни яктан бераз якынрак булган цитаталарны сайладым.

[13] Мәсәлән, тәнкыйтьче Евгений Аничков (1866-1937) символист-шагыйрьләр турында болай дип яза: «Алар Көнбатышның яңа чыганакларыннан мөмкин булган кадәр эчеп торганнар» (кара: [24: 176])

ниндидер яшерен, сихерле нәрсәләрне тасвирламыйлар, алар «бигрәк тә магик тере реальлекне чагылдыралар, шулай итеп ул реальлек объектив яктан күрсәтелә һәм бәяләнә». [27: 32]. Нәкъ бу фикерне Карл Шапиро Уолт Уитмен иҗатына карата куллана: «Шигърият – ул дөньяның метафорик яки символик версиясе генә түгел, ул турыдан-туры реальлекне тасвирлау» [28: 32]. Димәк, биредә сүз «дөреслек», «туры сүзлелек» турында бара. Бу – рус символистлары тарафыннан югары бәяләнгән һәм алар тарафыннан Уолт Уитмен иҗатында табылган «яшәешнең тулылыгын бөтен яктан дөрес тасвирлау» принцибы – «үз эченә барлык өстәмә процессларны да алып торган: җимерүне дә, яңарыш-тудыруны да» [24: 182].

Әгәр дә рус символистлары һәм өлешчә аларның «остазлары» (мәсәлән, Федор Тютчев) [29: 9, 14, 37, 42, 80] тарафыннан поэзиянең урыны турында әйтелгән сүз-фикерләрне Дәрдемәнд лирикасы белән чагыштырып карасак, охшашлыклар һәм тәңгәл килүләр бик ачык: әхлакый һәм сәяси аныклыктан баш тарту, аның урынына әдәбият белән сәнгатьнең үзбилгеләнү хокукын таләп итү, «реальлекне», шул исәптән, узганнарны да, чынбарлыкны да «үткен» күз белән хисләр-кичерешләр төрлелеге аша кабул итү; мәгънә белән яңгыраш берләшкән һәм, укучының хыялын чикләмичә, уйланырга һәм ирекле кош кебек очып йөрергә мөмкинлек бирә торган төгәл һәм лаконик тел. Мондый шигърият баштан ук чиксез дөньяның бар ягын кабул итүгә теләк һәм омтылыш белән аерылып тора.

Түгәрәк шул рәвешле ябыла. Биредә мин, «Дәрдемәнд һәм бөтендөнья әдәбияты» темасына нисбәтле кайбер фикерләремне белдереп, зур бәйләнеш конструкциясен төзүгә йөз тотмадым. Бу очракта минем өчен иң әһәмиятлесе шул: XIX йөзнең ахырында – XX йөз башында дөньяның төрле почмакларында, төрле тарихи, мәдәни, тел традицияләре булган шагыйрьләр нәкъ бер юнәлештә фикер йөртә башлыйлар. Аларның әсәрләре бер ритмда – «дөнья рухында» – сулыш алалар, алар иҗат иткән һәм шул рухны чагылдарган тел – ул «дөнья теле». Бөтен дөнья шагыйрь Дәрдемәнд өчен Ватан булган.

**Әдәбият**


1. *Дәрдмәнд әсәрләре* / Төз.: И.Рәми. Казан: Яңалиф, 1928. 108 б.
2. *Пушкин А.С.* Полное собрание сочинений в 10 томах. Т.3: Стихотворения (1827-1836). Л., 1977. 558 с.
3. *The English and Scottish Popular Ballads*. In five volumes. Ed by Francis James Child, vol. 1. New York (reprint 1882). 335 p.
4. *Grossman* J. D. Voron: Notes on the Purposes and Cross-Purposes of Translation // Mnemozina. Studia litteraria russica in honorem Vsevolod Setchkarev, hrsg. v. Joachim T.Baer, Norman W. Ingham. München, 1974. P. 153-162; *Weissberg* L., Edgar Allan Poe. Stuttgart, 1991. P. 184-190.
5. *Кәримев Ф.* Дәрдмәнд // Дәрдмәнд әсәрләре / Төз.: И.Рәми. Казан: Яңалиф,1928. 8-18 б.
6. *Сәйфи-Казанлы Ф.* Ни өчен Дәрдмәнд әсәрләрен басабыз // Дәрдмәнд әсәрләре / Төз.: И.Рәми. Казан: Яңалиф,1928. 100-101б.
7. *Нигъмәти Г.* Шагыйрь Дәрдмәнд һәм аның әдәби иҗаты // Дәрдмәнд әсәрләре / Төз.: И.Рәми. Казан: Яңалиф,1928. 19-37 б.
8. *Хәким С.* Шагыйрьнең осталыгы // Дәрдмәнд. Исә җилләр: Шигырьләр, истәлек-парчалар, вак хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр.,1980. 3-14 б.
9. *Дәрдмәнд.* Исә җилләр: Шигырьләр, истәлек-парчалар, вак хикәяләр. Казан: Татар. кит.нәшр., 1980. 254 б.
10. *Халит Г.* Дәрдмәнд // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3-том: XX гасыр башы. Казан:Татар. кит.нәшр., 1986. 194-214 б.
11. *Бурнаш Ф.* Тукай шигырьләрендә иҗтимагый моңнар (Тукайның үлүенә 9 ел тулу мөнәсәбәте белән // Татарстан хәбәрләре. 1922. № 87 (464). 17 апрель; *Мортазин С.* Иске мирастан файдалану мәсьәләсе // Кызыл Татарстан. 1929. № 280 (2650). 8 декабрь; *Хәсәнов Х.* Хөсәен Ямашев һәм татар демократик интеллигенциясе // Совет әдәбияты. 1952. № 3. 57-70 б.; *Фасеев К.Ф.* Әдәбиятта идеологик бозуларга каршы // Совет әдәбияты. 1954. № 8. 74-82 б.
12. *Сәйфи-Казанлы Ф.* Г.Тукай әсәрләрендә пародия, сатира, ирония һәм юмор // Г.Тукай әсәрләре. Т.3. Казан, 1931. III – XXXII б.; *Гали М.* Сәгыйть Рәмиевнең иҗат һәм тормыш юлы // Совет әдәбияты. 1940. № 4. 73-90 б.; *Хәйри Х.* Җавапсызлык хатына җавап // Совет әдәбияты. 1948. № 10. 115-122 б.; *Халит* Г. XX йөз башындагы татар әдәби хәрәкәтенең кайбер мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1950. № 1. 98-118 б.
13. *Тукай Г.* Кыйтга // Аң. 1913. № 6. 3б.
14. *Рәмиев С.* Сәгыйть Рәмиев шигырьләре. Өченче табгысы. Уфа: Шәрык, 1918. 45 б.
15. *Чулпон.* Яна олдым сузимни Т.: Адабиет ва санъат. 1991 / Ред. О.Шарафиддинов. Тошкент, 1991. 511 б.
16. *Christy A.* The Orient in American Transcendentalism. A Study of Emerson, Thoreau and Alcott. New York, 1963. 382 p.

17. *Chari V.K.* Whitman in India // Walt Whitman and The World. Ed by Gay Wilson Allen, ed Folsom. Iowa City, 1995. 468 p.
18. *Walt Whitman and The World*. Ed by Gay Wilson Allen, ed Folsom. Iowa City, 1995. 468 p.
19. *Miller J. E.* The Poetics of the Cosmic Poem // Walt Whitman and The World. Ed by Gay Wilson Allen, ed Folsom. Iowa City, 1995. P.49-50.
20. *Olney J.*The Language(s) of Poetry. Walt Whitmen, Emily Dickinson, Gerard Manley Hopkins. Athens-London, 1993. P. 44-45.
21. *Whitmen W.* Grashalme. Stuttgart, 1996. 182 p.
22. *Polonsk R.* Translating Whitman, Mistranslating Bal'mont // The Slavonic and East European Review. 1997. 75 (3). P. 401-421.
23. *Bernice S.* Start with the sun // James E. Miller, Karl Shapiro, Bernice Slote. Start with the sun. 1960. 260 p.
24. *Bidney M.* Leviathan, Earth-Titan, Eagle: Bal'monts Reimagining of Walt Whitman // Slavic and East European Journal. 1990. 34 (2). P. 176-191.
25. *Stepancev S.* Whitman in Russia // Walt Whitman and The World. Ed by Gay Wilson Allen, ed Folsom. Iowa City, 1995. 468 p.
26. *Holthusen J.* Russische Gegenwartsliteratur I, 1890-1940. Die literarische Avantgarde. Bern-München, 1963. 326 p.
27. *Holthusen J.* Studien zur Ästhetik und Poetik des russischen Symbolismus. Göttingen, 1957. 159 p.
28. *Shapiro K.* Cosmic Consciousness // James E. Miller, Karl Shapiro, Bernice Slote, Start with the sun. 1960. 260 p.
29. *Schulze A.* Tjutčevs Kurzlyrik. München, 1968. 97 p.

# ТВОРЧЕСТВО ДЭРДМЕНДА В КОНТЕКСТЕ МИРОВОЙ ЛИТЕРАТУРЫ

**Михаэль Фридерих,**
Бамбергский университет (Германия),
gilyazov1958@mail.ru.

В статье анализируется творчество поэта Дэрдменда, снискавшего мировую известность. Раскрывается мастерство поэта в создании образов, глубина философско-мировоззренческой проблематики и особенности его творчества. Автор статьи акцентирует внимание на специфике мотивов родины, родной земли, нации, рода в стихотворениях поэта и, рассматривая поэтический мир Дэрдменда в контексте литературно-культурных связей, выявляет типологические аналогии между его творчеством и литературами Запада и Востока. Дэрдменд как поэт, живший и творивший в эпоху становления разных литературно-эстетических систем, с присущей ему индивидуальностью сумел показать всю глубину внутреннего мира и переживаний личности того времени.

**Ключевые слова:** лирика, поэт, литературные взаимосвязи, мир, реальная жизнь, временное, вечность, грусть, слова, тема-мотив.